*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл** ________ ___________________ **Шифр** _____________
(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур**
**2017-2018 учебный год**
**9 класс**

**I. Сүзләрне фразеологик синонимнары белән алыштырып языгыз. /** Замените предложенные слова фразеологическими синонимами. (10 баллов).

1) **Күп** -
2) **Матур** -
3) **Хурлык** -
4) **Тәкъдир** -
5) **Тиле** –
6) **Надан** -
7) **Аңлап алу** -
8) **Уку** -
9) **Эндәшмәү** –
10) **Якында** -

**II. Басымы беренче иҗеккә төшкән сүзләрне язып алыгыз. /** Выпишите слова, в которых ударение ставится на первый слог. (10 баллов).

Һәркем Яңа елны күңелле каршыларга тели. Кайда гына булсаң да, син якыннарыңа сәламәтлек, бәхет-шатлыклар, уңышлар телисең. Һәрберебез киләсе елның имин булуын, сугыш афәтләре күрсәтмәвен, ләкин муллык, байлык алып килүен юрый. Шулай булсын! Теләкләр тормышка ашсын!

___ ______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________

**III. Бирелгән ике сүзеннән мәкаль һәм әйтемнәрне тулысынча искә төшереп языгыз. /** Вспомните и составьте по двум данным словам пословицы и поговорки. (10 баллов)

Китап- белем; *Эт- бүре; Ач- тук*; Акрын- тиз; Тел- ил.

______________________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________________

**IV. Алынма сүзләрнең татарча эквивалентларын языгыз һәм мәгънәләрен аңлатыгыз. /** Укажите татарский эквивалент к иноязычным словам и объясните их значения. (10 баллов)

**Дебат –**____________________________________________________________

**Интуиция -** __________________________________________________________

**Интрига –** __________________________________________________________

**Приз –** ____________________________________________________________

**Каток –** ___________________________________________________________

**V. Бәхәсне чишегез һәм җавабыгызны аңлатыгыз. / Решите спор. Объясните свой ответ.** (15 баллов).

Ике кыз бәхәсләшә икән.

**Беренчесе:**

- “Кичен кызларның әниләре кайтты” җөмләсендә хәбәр дөрес кулланылмаган. Ул ия белән ярашмаган, - дигән.
- Юк, дөрес кулланылган. Барысы да үз урынында, барысы да ярашкан, - дигән икенчесе.

Кем хаклы? Бәхәсне ничек чишәргә?

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

**VI. Нәрсә ул калька? Татар телендә калькалаштырылган сүзләр турында сез нәрсәләр беләсез? Фикерегезне мисаллар белән дәлилләп языгыз. /** Что такое калька? Что вы знаете о калькированных словах в татарском языке? Приведите примеры и объясните свой ответ. (10 баллов).

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

**VII. Татар халкының язу тарихы турында ниләр беләсез? Шул турыда языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. /** Что Вы знаете об истории письменности татар? Напишите об этом. Обоснуйте свое мнение примерами.(15 баллов).

*Исправления не допускаются*

**VIII. "Матур кешеләр нинди була?" дигән сорауга җавап биреп, 70 сүздән ким булмаган инша язызыз. Фикерегезне раслап, 2дән ким булмаган дәлил китерегез.** /Напишите сочинение (не менее из 70 слов) ответив на вопрос " Какими бывают красивые люди?" . Приведите не менее 2 довода-примера (20 баллов).

*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл ________ __________________** **Шифр _____________**
(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур (ответы)**
**2017-2018 учебный год**
**9 класс**

**I. Сүзләрне фразеологик синонимнары белән алыштырып языгыз. /** Замените предложенные слова фразеологическими синонимами. (10 баллов. *За каждый правильно приведенный фразеологический эквивалент по 1 баллу* ).

1) **Күп** - тавык чүпләп бетерерлек түгел, гарык булганчы, исәпсез-хисапсыз һ.б.
2) **Матур** - күз явын алырлык, бер кашык су белән йотарлык һ.б.
3) **Хурлык** - адәм мәсхәрәсе, адәм хуры, адәм рисвае һ.б.
4) **Тәкъдир** - ләүхелмәхфүзгә язылган, тәкъдиреңә язылган. Ходай язган, һ.б.
5) **Тиле –** акылга таман, 100гә бер җитми, акылга сай... һ.б.
6) **Надан** - әлифне таяк дип белмәү, аягыннан селкесәң бер хәреф тә төшмәс һ.б.
7) **Аңлап алу -** башка килү, искә төшү һ.б.
8) **Уку** - белем эстәү, энә белән кое казу, гыйлем алу һ.б.
9) **Эндәшмәү –** авызга су кабу, актан, карадан сүз катмау һ.б.
10) **Якында** - борын төбендә генә, астындагын ярты ай эзләгән, һ.б.

**II. Басымы беренче иҗеккә төшкән сүзләрне язып алыгыз. /** Выпишите слова, в которых ударение ставится на первый слог. (10 баллов. *За каждый правильный ответ по 2 балла).*

Һәркем Яңа елны күңелле каршыларга тели. Кайда гына булсаң да, син якыннарыңа сәламәтлек, бәхет-шатлыклар, уңышлар телисең. Һәрберебез киләсе елның имин булуын, сугыш афәтләре күрсәтмәвен, ләкин муллык, байлык алып килүен юрый. Шулай булсын! Теләкләр тормышка ашсын!

**Ответы:Һәркем, кайда, син, һәрберебез, ләкин**

**III. Бирелгән ике сүзеннән мәкаль һәм әйтемнәрне тулысынча искә төшереп языгыз. /** Вспомните и составьте по двум данным словам пословицы и поговорки. (*10 баллов. За каждую пословицу или поговорку по 2 балла)*

*Китап- белем; Эт- бүре; Ач- тук; Акрын- тиз; Тел- ил.*

*Киап- белем чишмәсе; Эт өрә торыр, бүре йөри торыр; Ачның хәлен тук белмәс; Акрын барган- тиз җитәр, Теле барның иле бар.*

**IV. Алынма сүзләрнең татарча эквивалентларын языгыз һәм мәгънәләрен аңлатып языгыз. /** Укажите татарский эквивалент к иноязычным словам и объясните их

значения. (10 баллов. За каждый ответ: 1 *балл - за краткий верный ответ + 1 балл – за верное толкование.*)

**Дебат** – бәхәс ( фикер алышу, үз фикереңне яклап чыгыш ясау)

**Интуиция** - сиземләү, тоемлау. (элекке тәҗрибәгә таянып сиземләү)

**Интрига** – мәкер ( берәр максатка ирешү өчен, астыртын алып барыла торган эш)

**Приз** – бүләк (котлап, рәхмәт белдереп бирелгән әйбер)

**Каток** – шугалак (тимераякта шуу өчен, боз белән капланган махсус мәйдан) .

**V. Бәхәсне чишегез һәм җавабыгызны аңлатыгыз. / Решите спор. Объясните свой ответ.** (15 баллов. 5 *баллов - за краткий верный ответ + 10 баллов – за верное обоснование*).
Ике кыз бәхәсләшә икән.
Беренчесе:

- “Кичен кызларның әниләре кайтты” җөмләсендә хәбәр дөрес кулланылмаган. Ул ия белән ярашмаган, - дигән.
- Юк, дөрес кулланылган. Барысы да үз урынында, барысы да ярашкан, - дигән икенчесе.

Кем хаклы? Бәхәсне ничек чишәргә?

**Җавап:**
**Ике кыз да хаклы, чөнки татар телендә өченче зат күплектәге тартым кушымчасы (-лары/-ләре) затның берлеген дә, күплеген дә белдерә ала.**
**Беренче кыз хаклы, чөнки ул ике яки күбрәк кызларның һәрберсенең үз әнисе кайтты дип уйлаган. Бу очракта фигыль күплектә кулланыла ала.**
**Икенче кыз исә ике яки күп бертуган кызларның әниләре кайтты дип уйлаган. Бу очракта кызлар күп, ә әниләре 1генә һәм ул кайтты.**

**VI. Нәрсә ул калька? Татар телендә калькалаштырылган сүзләр турында Сез нәрсәләр беләсез? Фикерегезне мисаллар белән дәлилләп языгыз. /** Что такое калька? Что Вы знаете о калькированных словах в татарском языке? Приведите примеры и объясните свой ответ. (10 баллов. 2 *балл - за краткий верный ответ +8 баллов – за верное обоснование с примерами*).

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Җавап: Калька – теге яки бу сүзне кисәкләп- морфемалап бер телдән икенче телгә тәрҗемә итеп, барлыкка килгән сүз. Тәрҗемә сүзгә-сүз, элементка-элемент булырга мөмкин. Мондый сүз ясалышын калькалаштыру диләр. Калькалаштырганда, чит тел сүзенең морфологик төзелеше саклана. Мәсәлән, озеленение- яшелләндерү, объединение – берләшмә. Һ.б.Сүз ясалыш калькалары һәм мәгънәви калькалар була. Сүз ясалыш калькалары морфологик кисәкләрне тәрҗемә иткәндә барлыкка килә: единство – бердәмлек, показатель – күрсәткеч.
Семантик калькалар вакытында сүзнең мәгънәсе чит телдәгечә кала, ә сүз үзе татарчалаша: Яшь натуралистлар *түгәрәге* (*кружок* юных натуралистов); *сайлаула*р башлана (начнутся *выборы*). Ярым калькалар да була : спецвагон- махсус вагон, воздушный флот – һава флоты ...

*Исправления не допускаются*

**VII. Татар халкының язу тарихы турында ниләр беләсез? Шул турыда языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез.** / Что Вы знаете об истории письменности татар? Напишите об этом. Обоснуйте свое мнение примерами.(15 баллов 5 *баллов - за краткий верный ответ + 10 баллов – за верное обоснование с примерами*).

Җавап: Татар язьы тарихында түбәндәге этаплар булган:

1) Рун язуы (7-10 гасырлар)
2) Гарәп язуы (10-20 гасыр)
3) уйгур язуы; (13-15 гасырлар)
4) латин язуы (1927- 1939)
5) Кирилл язуы (1939- бүгенге көнгәчә)

Һәр язуының үз үзенчәлекләре һәм үз кагыйдәләре бар. Хәзерге язу вариантларында да аларның кайбер үзенчәлекләре сакланып калган.

**VIII. "Матур кешеләр нинди була?" дигән сорауга җавап биреп, 70 сүздән ким булмаган инша языгыз. 2дән ким булмаган дәлил китерегез.** /Напишите сочинение (не менее из 70 слов) ответив на вопрос " Какими бывают красивые люди?" . Приведите не менее 2 довыда – примера (20 баллов).

| № | **Сочинениене бәяләү критерийлары** | **Баллар** |
|---|---|---|
| ***I*** | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |

| | | |
|---|---|---|
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| | **Язма эш өчен максималь балл** | **20** |

*Исправления не допускаются*